ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

27.03.2024 г. Казань № 12-2/тэ-2024

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024 елга «Газпром теплоэнерго Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан Менделеевск муниципаль районы кулланучылары тәэмин ителә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 20.12.2023 ел, №825-98/тэ-2023 карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Газпром теплоэнерго Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.03.2024 ел, №6-ПР беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2024 елга «Газпром теплоэнерго Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан Менделеевск муниципаль районы кулланучылары тәэмин ителә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 20.12.2023 ел, №825-98/тэ-2023 карарының үз көчен югалтуын танырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев